ГЛАВА ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЕДИНОАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Лебедино **КАРАР**

**30.10.2019г.** **№5**

**Алексеевского муниципаль районының “Лебедино җирлеге территориясендәге Лебедино авылында үзара салым кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында “**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Лебедино җирлеге территориясендәге Лебедино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 10 нче ноябре көнне 15сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Алексеевск муниципаль районы Лебедино җирлеге территориясендәге Лебедино авылында 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә даими яшәүче теркәлгән,балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю, төзекләндерү һәм карап тоту;
- техниканык карап тоту (тракторлар, УАЗ автомашиналары, янгын сүндерү автомашиналары, килешү буенча хезмәт хакы);

- авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм килешү буенча хезмәт хакы түләү;

-җирлек территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы территориясен койма белән әйләндереп алу һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга һәйкәл кую өчен төзелеш материаллары сатып алу, агач кисү, триммер сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү).

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

3.Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4.Җыенның үткәрү урыны дип авыл мәдәният йортын билгеләргә.Адресы: Татарстан Республикасы.Алексеевск районы, Лебедино авылы, Кооперативная урамы 13А йорт

5. Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Лебедино авылы, Кооператив урамы, 3, Лебедино авылы, Кооператив урамы, 3А, Лебедино авылы, Совет урамы, 65А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Ю.И.Тюкарев**